ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасының аерым закон актларына коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 27 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда:

а) 2 өлештә «коррупциячел хокук бозуларны профилактикалау буенча вәкаләтле» сүзләрен «коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше буенча җаваплы» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлешнең беренче абзацында «Муниципаль вазыйфа яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче зат» сүзләреннән соң «(авыл җирлекләренең вәкиллекле органнары депутатлары муниципаль вазыйфаларын биләүче һәм үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә башкаручы затлардан тыш)» сүзләрен өстәргә;

в) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ өлеш өстәргә:

«$4^1$. Авыл җирлегенең вәкиллекле органы депутаты муниципаль вазыйфасын биләүче һәм үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә башкаручы зат керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләрне депутат булып сайланган, аңа вакантлы депутат мандаты тапшырылган яисә ул даими нигездә вәкаләтләр башкаруны туктаткан көннән алып дүрт ай эчендә, шулай ук, хисап чоры дәвамында «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килүне тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның

3 статьясындагы 1 өлешендә каралган алыш-бирешләр ясалган очракта, белешмәләр тапшыру елына кадәрге һәр ел (хисап чоры) өчен тапшырыла. Хисап чоры дәвамында шундый алыш-бирешләр ясалмаган очракта, күрсәтелгән зат бу хакта, әлеге статьяның 2 өлешендә каралган махсуслаштырылган мәгълүмат ресурсыннан файдаланып, әлеге Законга кушымтада бирелгән рәвештә Татарстан Республикасы Президентына хәбәрнамә җибәрә. Әлеге өлештә каралган хәбәрнамә, шулай ук белешмәләр (хисап чоры дәвамында «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килүне тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган алыш-бирешләр ясалган очракта) хисап чорыннан соң килә торган елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

Хәбәрнамәнең авыл җирлегенең вәкиллекле органы депутаты муниципаль вазыйфасын биләүче һәм үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә башкаручы зат тарафыннан имзаланган кәгазь күчермәсе тиешле муниципаль районда (шәһәр округында) коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше буенча җаваплы вазыйфаи затка җибәрелә һәм законнар нигезендә сакланырга тиеш була.»;

2) 3 статьяның 3 өлешендә «4 өлешендә күрсәтелгән вакыт» сүзләрен «4 һәм $4^1$ өлешләрендә күрсәтелгән вакыт» сүзләренә алмаштырырга;

3) түбәндәге эчтәлекле кушымта өстәргә:

«Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законына кушымта

Татарстан Республикасы Президенты

____________________________________

Хәбәрнамә

Мин, ________________________________________ муниципаль районы
муниципаль район исеме

_____________________________________________ авыл җирлеге депутаты
авыл җирлеге вәкиллекле органы исеме

____________________________________________________________________,
фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта)

_______ елның «___»___________ туган, паспорт сериясе ______ №___________,

____________________________________________________________________,
паспорт бирелгән дата һәм биргән орган

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның $12^1$ статьясындагы $4^2$ өлеше, «Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы $4^1$ өлеше нигезендә Сезгә түбәндәгеләрне хәбәр итәм: 20 ___ елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге хисап чоры дәвамында минем тарафтан, хатыным (ирем) һәм (яисә) балигъ булмаган балаларым тарафыннан «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килүне тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган алыш-бирешләр (гомуми суммасы безнең (минем һәм хатынымның (иремнең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елда алган гомуми керемнән артык булган, җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлешләре, пайлар) алу буенча алыш-бирешләр) ясалмады.

Әлеге белешмәләрнең дөреслеген раслыйм.

«____»____________ 20__ ел

____________________________________
хәбәрнамә тапшырган зат имзасы

________________________________________________________________________
(хәбәрнамәне алырга вәкаләт бирелгән затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) һәм имзасы)».

**2 статья**

«Муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» 2017 елның 19 июлендәге 57-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2019, № 60 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 өлештә «вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату» сүзләреннән соң «яисә күрсәтелгән затларга карата башка җаваплылык чаралары күрү» сүзләрен өстәргә;

2) түбәндәге эчтәлекле $7^1$ өлеш өстәргә:
«$7^1$. Керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына, әлеге белешмәләрне бозып күрсәтү зур әһәмияткә ия булмаганда, түбәндәге җаваплылык чаралары каралырга мөмкин:
1) кисәтү;
2) депутатны, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын, вәкаләтләре чоры тәмамланганчы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфа биләү хокукын бетереп, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органындагы, җирле үзидарәнең сайланулы органындагы вазыйфасыннан азат итү;
3) вәкаләтләре чоры тәмамланганчы даими нигездә вәкаләтләр башкару хокукын бетереп, даими нигездә вәкаләтләр башкарудан азат итү;
4) вәкаләтләре чоры тәмамланганчы муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфа биләүне тыю;
5) вәкаләтләре чоры тәмамланганчы даими нигездә вәкаләтләр башкаруны тыю.»;

3) түбәндәге эчтәлекле $7^2$ өлеш өстәргә:
«$7^2$. Татарстан Республикасы Президентының әлеге статьяның $7^1$ өлешендә каралган җаваплылык чаралары (алга таба – җаваплылык чаралары) күрү турындагы гаризасы әлеге җаваплылык чараларын күрү турында карар кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан әлеге органга шундый гариза кергән көннән алып 30 көннән дә соңга калмыйча карала. Җаваплылык чаралары күрү турында карар кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органының төп эш рәвеше сессияләрдән гыйбарәт булса һәм Татарстан Республикасы Президентының җаваплылык чаралары күрү турындагы гаризасы сессияләр арасындагы чорда кергән булса, әлеге гариза кергән көненнән алып өч айдан да соңга калмыйча карала. Татарстан Республикасы Президенты гаризасын карау нәтиҗәләре буенча

җаваплылык чарасы күрү турында йә җаваплылык чарасын күрүдән баш тарту хакында карар кабул ителә.

Хисап чорында керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен бер генә төрле җаваплылык чарасы күрелергә мөмкин.

Керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына аңа карата җаваплылык чаралары күрү турындагы мәсьәләне карау хакында әлеге затка җаваплылык чаралары күрү турында карар кабул итәргә вәкаләтле орган тарафыннан аңа карата күрсәтелгән чаралар күрү турындагы мәсьәләне карау датасына кадәр кимендә биш эш көне кала язмача хәбәр ителә.

Җаваплылык чарасы күрү турында карарда коррупциячел хокук бозу, депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты тарафыннан бозылган норматив хокукый актлар нигезләмәләре, Россия Федерациясе законнарында күрсәтелгән тәртиптә карарга шикаять белдерү хокукы күрсәтелергә тиеш.

Җаваплылык чарасы күрүдән баш тарту турындагы карарда мондый баш тартуның дәлилләнгән нигезе күрсәтелергә тиеш.

Җаваплылык чарасы күрү турындагы яисә җаваплылык чарасы күрүдән баш тарту хакындагы карарның күчермәләре кабул ителгән көненнән алып биш эш көне эчендә, алынуы турында имза куелып, депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына тапшырыла йә тапшырылуы турында хәбәр ителә торган хат белән почта аша җибәрелә, шулай ук Татарстан Республикасы Президентына җибәрелә.

Җаваплылык чарасы күрү турындагы яисә җаваплылык чарасы күрүдән баш тарту хакындагы карарга Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерелергә мөмкин.

Депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата җаваплылык чаралары күрү турында карар кабул итү тәртибе, әлеге статья нигезләмәләрен истә тотып, муниципаль хокукый акт белән билгеләнә.».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 09 декабрь
№ 99-ТРЗ